Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

**КАРАР №37**

Урыссу штп "17"_____12_ 2018 ел

«ТР Ютазы муниципаль районының
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында» 26.01.2018 ел,
№1 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә чисталык, тәртип саклау һәм төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Җирлекләрнең, шәһәр округларының, шәһәр эчендәге районнарның территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында» 3.04.2017 ел, 711/пр боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Урыссу шәһәр тибындагы поселогының "Тышкы реклама чаралары» территория төзекләндерү кагыйдәләрен (4.6.11. п) тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.6.11.1. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан тәртипкә салынган булырга тиеш.

Тышкы мәгълүмат чаралары, гамәлгә кую такталары һәм режим табличкаларыннан тыш, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорт нигезендә һәм аңа ярашлы урнаштырыла һәм эксплуатацияләнә.

4.6.11.2. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары хуҗалары аларның торышын тиешенчә күзәтеп торырга, аларны вакытында ремонтларга

һәм тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын җыештырырга тиеш.

4.6.11.3. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын реклама яки мәгълүмати хәбәр язмыйча урнаштыру һәм эксплуатацияләү, мәгълүмат кырына зыян китерү, шулай ук тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларына полиэтилен пленка һәм башка материаллар ябыштыру һәм аларга элеп кую рөхсәт ителми.

4.6.11.4. Биналар фасадларына, корылмаларның һәм киоскларның тышкы диварларына, коймаларга һәм ихаталарга, павильоннарга, яктырту баганаларына, реклама конструкцияләренә һәм тышкы мәгълүмат чараларына, агачларга һәм асфальтларга белдерүләр һәм мәгълүмати хәбәрләр урнаштыру, шулай ук язулар һәм рәсемнәр ясау рөхсәт ителми.

4.6.11.5. Реклама яки мәгълүмат конструкциясе хуҗасы территорияне төзекләндерү һәм (яисә) фасадның тышкы күренешен өч тәүлек дәвамында монтажлаганнан соң (демонтажлаганнан соң) торгызырга тиеш.

4.6.11.6. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары, аларда нигез блогы булганда, нигез блогы белән бергә сүтелергә тиеш.

4.6.11.7. Объектларның тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын беркеткәндә корылмаларына һәм бизәкләренә зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын һәм тотрыклылыгын киметү рөхсәт ителми.

4.6.11.8. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

- дивар конструкциясе;
- декоратив панно;
- консоль конструкция;
- түбә конструкциясе;
- витрина конструкциясе;
- учреждение тактасы;
- режим табличкасы;
- модуль конструкциясе;
- стела;
- щит конструкциясе;
- флаг композициясе;
- махсуслаштырылган конструкция.

4.6.11.9. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларына гомуми таләпләр:

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларын проектлау, әзерләү һәм урнаштыру төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәле) турында Россия Федерациясе законнары таләпләре, аларны саклау һәм куллану таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш; тышкы мәгълүмат чараларына мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш;

Ике һәм аннан да күбрәк тел кулланылган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тигез булырга, дөрес һәм аңлаешлы итеп башкарылырга тиеш.

4.6.11.10. Гражданнар белдерүләрен, мәдәни һәм спорт чараларын урнаштыру афишалары өчен җайланмалар.

Игъланнарны, мәдәни һәм спорт чаралары афишаларын урнаштыру, бары тик гражданнар күпләп йөри торган урыннарда һәм җәяүлеләр җанлы зоналарындагы махсус тумбаларда, щитларда һәм стендларда гына рөхсәт ителә. Игъланнар өчен стендлар аерым торган объектлар рәвешендә яисә биналарда яки корылмаларда асылмалы щитлар рәвешендә урнаштырыла ала.

1.2. «Территориянең бәйрәм бизәлеше» 4.9 пунктка үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

4.9.1. Поселок территориясен бәйрәм һәм тематик бизәү, түбәндәге исемлек буенча чаралар һәм бәйрәм көннәрендә башкарыла:

1. Яңа ел каникуллары (1, 2, 3, 4, 5, 6 һәм 8 гыйнвар)
2. Раштуа бәйрәме (7 гыйнвар)
3. Ватанны саклаучылар көне (23 февраль)
4. Халыкара хатын-кызлар көне (8 Март)
5. Россиядә Җирле үзидарә көне (21 апрель)
6. Яз һәм Хезмәт бәйрәме (1 Май)
7. Җиңү көне (9 май)
8. Россия көне (12 июнь)
9. Хәтер һәм кайгы көне (22 июнь)
10. Россия Федерациясенең Дәүләт флагы көне (22 август)
11. Татарстан Республикасы көне (30 август)
12. Белем көне (1 сентябрь)
13. Халыклар бердәмлеге көне (4 ноябрь)
14. Татарстан Республикасы Конституциясе көне (6 ноябрь)
15. Бердәмлек һәм татулык көне (7 ноябрь)
16. Россия Федерациясе Конституциясе көне (12 декабрь)

Биналарны, корылмаларны бизәү поселок территориясен бәйрәмчә бизәү концепциясе кысаларында аларның хуҗалары яки арендаторлары тарафыннан башкарыла.

4.9.2. Бәйрәм бизәлешенә милли флаглар, лозунглар, гирляндалар, панно, декоратив элементлар һәм композицияләр, киоск стендлары, трибуналар, эстрадалар, шулай ук бәйрәм иллюминациясе җайланмасы урнаштыру керә.

4.9.3. Бәйрәм һәм тематик бизәлеш объектларның әзерлеге бәйрәм датасына кадәр - 5 көн алдан, Яңа елга - 20 декабрьдән билгеләнә.

4.9.4. Россия Федерациясе Дәүләт флагын, Татарстан Республикасы флагын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре флагларын бәйрәм

бизәлешендә һәм башка чараларда куллану «Россия Федерациясе Дәүләт флагы турында» 2000 елның 25 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел Законда, «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4.9.5. Бәйрәмчә бизәлеш элементларын ясаганда һәм урнаштырганда юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларын төшерергә, зыян китерергә һәм начарайтырга ярамый.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы-
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.М. Нуриев